## **Читекләр**

1) Аягымда читекләр
Үзләре биетәләр,
Күбәләктәй очыртып гел
Сәхнәдә йөретәләр.

Кушымта:
Эх, чигүле читекләр,
Аллы - гөлле бизәкләр,
Үкчәләрдән утлар оча
Ялкынлангач йөрәкләр.

2) Тыпыр, тыпыр, тыпырдый
Берничә дә карамый,
Дәртле, матур, шәп көйләргә
Читекләрем тик тормый.

3) Читекләрне киямен,
Мин булдырам, - диямен,
Җыр - биюле балачакның
Кадерләрен беләмен.

4) Бөтереләм, әйләнәм
Җырларга да өлгерәм,
Куллар чапкан һәрберсенең
Кәефләрен күтәрәм.